ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04 сентября 2020 г. № 4391

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында» 2016 елның 25 октябрендәге 5610 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасына үзгәрешләр кертү хакында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын раслау турында» 2016 елның 25 октябрендәге 5610 номерлы карары (Башкарма комитетның 2017 елның 15 сентябрендәге 5527 номерлы, 2017 елның 17 ноябрендәге 7048 номерлы, 2018 елның 7 маендагы 2523 номерлы, 2018 елның 18 октябрендәге 6197 номерлы, 2019 елның 30 апрелендәге 2266 номерлы, 2019 елның 11 ноябрендәге 5788 номерлы, 2020 елның 17 мартындагы 1259 номерлы, 2020 елның 30 мартындагы 1556 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасына, кушымтада каралганча пунктлар өстәп, үзгәрешләр кертергә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2020 елның 4 сентябрендәге
4391 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасы

| № т/б | Объектның урнашу урыны (адресы) | Объектның тибы | Объект чикләренең борылыш нокталары координаталары | Объектның махсуслашуы | Объекттан файдалану |
|---|---|---|---|---|---|
| Үзәк районы | | | | | |
| 172.18 | 40/09А торак йорт районы | Киоск 8.1 кв.м. | 470075.474 2322192.061<br>470074.681 2322194.954<br>470072.078 2322194.241<br>470072.871 2322191.348 | Басма продукция сату | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары |
| 172.19 | «Лесное» күле районы | Киоск 3 кв.м. | 472339.388 2322565.966<br>472340.806 2322565.249<br>472341.650 2322566.950<br>472340.250 2322567.660 | Шикәр мамыгы, попкорн һәм кукуруз сату | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары |
| 172.20 | Сәнәгать-коммуналь зонасы, Хлебный тыкрыгы, 7 | Павильон 35 кв.м. | 467014.409 2323782.718<br>467017.986 2323779.226<br>467022.875 2323784.235<br>467019.297 2323787.727 | Алкоголь продукциясе (шул исәптән сыра) һәм спиртлы продукция сату хокукыннан тыш азык-төлек товарлары | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы — Н.И. Галиева